Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№ 7 (7)

17 ноябрь 2011 ел

## Ике авыз сүз

14 ноябрь көнне ректорат утырышы узды. Көн тәртибенә Корея Республикасына бару (тышкы элемтәләр буенча проректор Л.Латыйпов чыгыш ясады), җитәкчелекнең студентлар белән узган очрашуы вакытында билгеләнгән максатларның тормышка ашырылуы, 2012 елга абитуриентлар кабул итү эшенең барышы һәм Барнаулда узган Бөтенроссия студентлар форумында катнашу нәтиҗәләре турында сөйләшү куелган иде. В.П.Энгельгард исемендәге обсерваториянең дәрәҗәсен һәм тәзелешен үзгәртү мәсьәләсе дә каралды. Соңгы мәсьәләгә бәйле рәвештә, Физика институты директоры А.Аганов Кафедраара фәнни космик тикшеренүләр һәм технологияләр үзәген ачу проекты белән таныштырды. Үзәктә ике объект – обсерватория һәм «Радиофизик полигон» булачак. И.Гафуров астрономия өлкәсендә нинди яңалыклар булуы белән кызыксынды. Космосны «кайтару» өлкәсенә басым ясарга кирәклеген әйтте.

Алга таба Кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе С.Ионенко чыгыш ясады. Тәбәкара Интернет олимпиадасының беренче сессиясенә нәтиҗәләр ясалды. С.Ионенко сүзләренә караганда, быел катнашучылар 3,5 тапкырга арткан. I курс студентлары быел РФнең 65 төбәгеннән килүе КФУның ни дәрәҗәдә популяр булуын күрсәтә.

Ректорның студентлар белән очрашуы турында уку-укыту эшләре буенча проректор Р.Минзарипов сөйләде, очрашуда күтәрелгән проблемалар һәм аларны чишү юлларын күрсәтте. «Аудиторияләр җитмәү, туклану урыннары булмау кебек мәсьәләләр вакытлы гына, алар тиз арада хәл ителәчәк», – диде ректор.

Социаль һәм тәрбия эшчәнлеге буенча проректор А.Межведилов студентларыбызның Барнаулда форумда катнашуы турында чыгыш ясады. Студентлар тәкъдим иткән җиде проектның өчесе бүләккә лаек. Проректор һәр якшәмбе саен КФУ хезмәткәрләре катнашында уза торган ярышлар турында да әйтеп узды һәм анда катнашучы һәркемгә рәхмәт сүзләре җиткерде. Укытучылардан актив студентларның хәленә керүләрен үтенде.

Утырышны ректор И.Гафуров университетның якынлашып килгән Туган көне белән котлап тәмамлады.

• • • •

6-11 ноябрь көннәрендә ректор И.Гафуров җитәкчелегендәге КФУ делегациясе Корея Республикасында булып кайтты. Корея фонды белән килешү төзелде. Аның нигезендә төбәкне өйрәнү һәм табигый фәннәр буенча икеякләы хезмәттәшлек тормышка ашырылачак. Шулай ук делегация вәкилләре «Инчхон» иркенле икътисади зона, алдынгы югары уку йортларының эшчәнлеге белән таныштылар. КФУ инде күп еллар дәвамында Кореянең фәнни-белем бирү үзәкләре белән хезмәттәшлек итә. Ректор Кукмин һәм Чонджу университетларында стажировка үтүче Казан университеты студентлары белән дә очрашты. Аларның корея телендә иркен аралашуы килешүләрнең уңай нәтиҗә бирүе турында сөйли.

• • • •

10 ноябрь көнне Н.И.Лобачевский исемендәге китапханәдә Халыкара студентлар олимпиадасының «Банклар көрәше» полуфиналы узды. Аны «Россия Саклык банкы» Россия Халык хуҗалыгы академиясе һәм РФ Президенты каршындагы дәүләт хезмәте белән берлектә уздыра. 10 команда арасында җиңү яулаган КФУның Яр Чаллы филиалы «Синергия» командасы Мәскәүдә үз көчен сынаячак.

• • • •

9 ноябрь көнне EDUNIVERSAL эксперт агентлыгы MBA программасының халыкара рейтингын игълан итте. Дөньяның 200 иң яхшы MBA программасы составында КФУ программасы да бар. EDUNIVERSAL рейтингында 153 илдән 1000 бизнес-мәктәп катнашты. Аларны 9 географик зонага бүлеп карыйлар. КФУның MBA программасы Үзәк Азия төбәгенә туры килә. Ул әлеге төбәктә Россиянең бердәнбер иң яхшы программасы санала.

*ksu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Алия Галимуллина фотосы

# Җитәкчеләр «студент» булды

**Рәдифә ШӘФЫЙКОВА,**
ksu.ru сайты хәбәрчесе

15 ноябрь көнне КФУның Икътисад һәм финанс институтында «Дәүләт һәм муниципаль оешма хезмәткәрләренең һөнәри өзерлекләрен үстерү» программасын ачу тантанасы узды.

Чараны ТР Президенты Аппараты җитәкчесе Юрий Камалтынов ачып җибәрде. Үз чыгышында ул курсларга бәйле проблемага басым ясады: «Бүгенге көндә җитәкчеләрнең яртысы диярлек үзләренең ни белән шөгыльләнгәнен, алларына нинди максат куелганны аңлап бетерми. Бу курслар аларга һәрьяклап үсәргә мөмкинлек бирә».

Казан федераль университеты ректоры Илшат Гафуров, катнашучыларны сәламләп: «Университетта үткән көннәрегез алга куйган бурычларыгызны дөрес хәл итүдә ярдәм булыр дип уйлыйм», – диде һәм уңышлар теләде.

Әлеге программа кыска вакыт эчендә (72 сәгать) квалификацияне арттырырга ярдәм итә. 300ләп тыңлаучы 3 төркемгә бүленгән: Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы вәкилләре; муниципаль хезмәткәрләр; дәүләт хезмәткәрләре.

Төркемнәр бергәләп курсның база өлешен, аннары, һөнәри юнәлешкә бәйле рәвештә, һәрберсе аерым-аерым вариатив өлешне тыңлаячак. База өлешенә хезмәткәрләрнең норматив-хокукый эшчәнлеген, IT-компетенцияләрен, сәяси һәм дини толерантлыгын, коррупциягә каршы культурасын, аралашу культурасын, лидерлык, команда белән эшли белү сыйфатларын арттыруга бәйле һ.б. модульләр кертелгән.

Программа йөзләп модуль нигезендә төзелгән булуы белән генә түгел, ә белем бирү процессында КФУ галим-мөгаллимнәреннән тыш, ТРның төрле министрлыкларыннан һәм идарәләрдән белгечләр катнашуы белән дә әһәмиятле. КФУның әлеге программасы ТР Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре буенча департамент белән берлектә төзелә. Димәк, теория белән практиканы бергә алып барырга, дәүләт һәм муниципаль идарә өлкәсендә тәҗрибә уртаклашырга ярдәм итәчәк.

2011 елда барлыгы шундый 45 программа тормышка ашырылган. Бу 1070 дәүләт хезмәткәре һәм 1414 муниципаль хезмәткәр катнашкан дигән сүз.

## Яңа ачыш

# Физиклар бүтән хаталанмас!

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

14-17 ноябрь көннәрендә Физика институтында «Лаборатор физик практикум һәм демонстрацион физик кабинет» семинар-презентациясе ачылды. Яңа лаборатор комплекс Leybold Didactic GmbH компаниясенең (Германия) яңа җиһазлары белән тәэмин ителгән.



Семинар-презентация югары уку йортларын яңа лаборатория белән тәэмин итү эшен алып бара. Россия күләмендә инде 22 шундый үзәк ачылган. Электр, оптик, молекуляр лабораторияләр тулысынча заманчалаштырылган. Иң мөһиме: алар организм өчен зыянлы түгел. Башта теориягә зур игътибар бирелгән булса, хәзер яңа юнәлеш буенча укытачаклар. Димәк, методика тулысынча үзгәрә дигән сүз. Мәктәп программасы буенча бу дәрәҗәдә күп әйберне өйрәнеп булмый. Әле яңа гына студент булган элеккеге укучылар физиканы бөтенләй башка яктан ачачак. Лабораториянең иң уңай ягы: хәзер күз белән карап, санап утырырга туры килмәячәк. Махсус җиһазлар ярдәмендә тикшерелгән саннар нәтиҗәсе туры компьютерга кертелеп барачак. Хаталарга урын калмый дигән сүз.

• Спорт фестивале – 2011

# Сәламәт тәндә - сәламәт акыл



**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

Бу көннәрдә Казаныбызның спорт сөючеләре аеруча бер күнелле халәт кичерә. Казан университетында федераль дәрәҗәдәге чаралар уза. Кызыксындырган сорауларга җавап табу максатыннан, Физик культура һәм тернәкләндерү медицинасы институты директоры Искәндәр Шамил улы ГАЛИЕВ белән сөйләштек.

***– Искәндәр Шамилевич, КФУның башка институтларына караганда, бу көннәрдә Сездә аерым бер җанлану сизелә, бу халәтне ничек аңларга?***

– 15 ноябрь көнне университетыбызда Россия Федерациясе вузларыннан биш йөздән артык вәкил һәм шулай ук Россиянең иң зур сигез федераль университетыннан (Иммануил Кант исемендәге Балтыйк университеты, Себер федераль университеты, Ерак Көнчыгыш федераль университеты, Төньяк (Арктика) федераль университеты, М.К.Аммосов исемендәге Төньяк-көнчыгыш федераль университеты, Россиянең Беренче Президенты Б.Н.Ельцин исемендәге Урал федераль университеты, Көньяк федераль университеты һәм Казан (Идел буе) федераль университеты) өч йөздән артык студент һәм укытучыларны каршы алдык. КФУ базасында ике зур чара – Студентлар спорты фестивале һәм Бөтенроссия күләмендә «Студентны шәхес буларак тәрбияләүдә физик культура һәм спортның ролен үстерү» дигән темага фәнни-гамәли конференция уза. Федераль вузларның һәм башка уку йортларының студентлары-аспирантлары үзләренең спорт һәм фән дөньясындагы уңышларын күрсәтә алачак.

**– Ә ни өчен бу зур чаралар нәкъ менә безнең шәһәрдә үткәрелә?**

– Россиякүләм мондый зур чараларның Татарстан башкаласында үткәрелүе очраклы түгел. Казан шәһәре 2013 елда XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиадасын үзендә үткәрергә хокук алгач, күп кенә заманча җиһазландырылган спорт корылмалары төзелде. Шулай ук Казан Россия шәһәрләре арасында спорт өлкәсендә иң алдынгылардан санала. Студентлар хәрәкәтенең үзәге дә монда. Шәһәребездә масштаблы мәдәни-спорт чараларын үткәрү буенча зур тәҗрибә тупланган. Мәсәлән, шактый спорт төрләре буенча Дөнья, Европа һәм Россия чемпионатларын уздыру, бигрәк тә РФ Президенты Дмитрий Медведев катнашында узган «Россия – спорт державасы» дип аталган Бөтенроссия форумын үткәрүнең әһәмияте зур булды.

***– Россия күләмендә беренче мәртәбә үткәрелә торган әлеге Спорт фестиваленең максаты нидән гыйбарәт?***

– Бу фестивальнең максаты – сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау һәм студентларның физик әзерлеген арттыру. Ярышта катнашучылар җиңел атлетика, өстәл теннисы, волейбол (кызлар), йөзү, кул көрәше, катнаш эстафета кебек спорт төрләре буенча көч сынаша.

***– Искәндәр Шамилевич, фестиваль көннәрендә үтә торган Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциянең эшчәнлеге турында да сөйләсәгез иде.***

– Конференциядә югары уку йортларында физик тәрбиянең әһәмияте, спорт өлкәсендә һөнәри белем бирү үсешенең перспективалары һәм проблемалары, 2013 елда узачак Универсиадага әзерлек турында фикер алышулар планлаштырыла. Пленар утырыштан соң «Предмет буларак физик культура: аның эчтәлегенә һәм тормышка ашырылуына заманча караш», «Югары уку йортларында физик культураның һәм спортның тәрбияви әһәмияте», «Физик культура һәм спорт өлкәсендә белгечләр әзерләү һәм яңа белгечлек бирү проблемалары» кебек секцияләр эшли. «Сәламәт яшәү рәвеше алып бара торган вуз» конкурсы җиңүчеләре булган Себер федераль университеты, Томск политехник милли-тикшеренү университеты, Россия халыклар дуслыгы университетының эшчәнлекләрен күрсәткән презентация дә әзерләнә. Ахырдан фестивальдә җиңүчеләрне бүләкләү көтә.

***– Искәндәр әфәнде, Сез җитәкчелек итә торган Физик культура һәм тернәкләндерү медицинасы институты оешып эшли башлаганга әле бер-ике ай гына. Коллективыгыз һәм киләчәккә планнарыгыз турында да беләсебез килә.***

– Хәзерге көндә безнең институтта 167 хезмәткәр эшли. Шуларның 13е – фән докторы, профессорлар; 53е – фәннәр кандидаты. Арабызда Халыкара дәрәҗәдәге спорт остасына кандидатлар, Россиянең бер атказанган спорт остасы һәм шулай ук Россия, Татарстан спорт остасына да кандидатлар бар. Педагогик юнәлештә төп бурычыбыз – мәктәпләр өчен физик культура укытучыларын, балалар спорт клублары өчен тренерлар әзерләү. Параллель рәвештә Универсиадага әзерлек алып барабыз.

Институтта 9 кафедра эшләп килә: «Физик культура теориясе кафедрасы», «Тормыш иминлеге кафедрасы», «Физик культураның медико-биологик нигезләре», «Спорт фәннәре кафедрасы», «Гимнастика һәм чаңгы спорты кафедрасы», «Анатомия, физиология һәм кеше сәламәтлеген саклау кафедрасы», 3 «Физик культура кафедрасы». Институтта бүгенге көндә уникe белгечлек буенча белем бирелә. Киләчәктә «сәламәтләндерү туризмы», «спорт медицинасы» кебек белгечлекләр ачарга җыенабыз.

***– Рәхмәт Сезгә, Искәндәр әфәнде. Эшләрегез уң булсын, зур җиңүләр яуларга язсын!***

# «Бер адымны чакрым итмик…»

Кичә «Бустан» спорт комплексында Студентлар спорты фестивале ачылды. Ректор Илшат Гафуров: «Вузлар алдында төп максатларның берсе булып спорт командалары әзерләү генә түгел, ә физик тәрбияне массакүләм дәрәҗәгә җиткерү тора», – диде.

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

Дөрестән дә, фестиваль сәламәт яшәү рәвешен пропагандалый, студентлар арасында спорт традицияләрен сакларга, дуслык күперләре салырга ярдәм итә. Үз-үзен җиңә алган кеше генә чын спортчы була ала. Уку йортының данын яклап, шундый дәрәҗәле ярышларда зур җиңүләргә омтылу өчен, рухи көчнең нык булуы мөһим. Фестивальгә килгән спортчылар үз алдына зур максатлар куйган. Төньяк (Арктика) федераль университетыннан килгән Дарья Дмитришина канәгать булып: «Тәҗрибә уртаклашырга кирәк. Күп спортчылар белән танышырга, фикер алышырга өлгердек инде. Оештыручыларга зур рәхмәт, барсы да югары дәрәҗәдә үтә», – диде.

### *Волейбол*

Волейбол ярышлары «Бустан» спорткомплексында үтә. Бу төр буенча көч сынашу кызлар арасында гына уза. Командалар бик көчле, ләкин кайсы команданың җиңү алып китәчәге фестивальне ябу тантанасында билгеле булачак.



Алия Галимуллина фотосы

### *Йөзү*

Спортның һәркайсы төре сәламәтлеккә уңай тәэсир ясый, әмма алар арасында сәламәтлекне ныгытуда иң яхшыларының берсе булып йөзү санала. Фестиваль кысаларында да бу төр буенча ярышлар үтә. Ирекле стильдә егетләр дә, кызлар да 100 һәм 200 метр озынлыкка йөзде. Шулай ук 100 метрга брасс, аркада йөзү һәм батерфляй төрләре буенча көч сынаштылар.

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

### *Җиңел атлетика*

Җиңел атлетика үз эченә берничә спорт төрен – төрле дистанциягә йөгерү, озынлыкка һәм биеклеккә сикерү, еракка ату һ.б. шундый оешкан спорт төрләрен ала. Бу көнне Үзәк стадионда яшьләр арасында 100, 400 метрларга йөгерү булды. Йөгереш бик җитди спорт төре. Аның өчен күп кирәк түгел: иркен мәйдан һәм уңайлы аяк киеме. Нәрсәсе белән үзенә тарта икән соң ул яшьләрне? Урал федераль университетыннан килгән яшьләр бертавыштан йөгерүнең бик файдалы булуын искәртеп узды. Йөгерү белән шөгыльләнгән кешенең тормышта имгәнүләр алу куркынычы күпкә азрак икән. Шулай ук барлык мускулларның да бертигез хәрәкәтләнүе, кан әйләнешен тәртипкә китерә.

Нәтиҗәләргә килгәндә, 100 м аралыкта кызлар арасында беренчелекне Анна Галунова (Балтыйк федераль университеты), ә егетләр арасында Валентин Иванов (Төньяк-көнчыгыш федераль университеты) алды. Үзебезнең Казан федераль университетыннан Людмила Артамонова II урынга лаек булды. 400 м ераклыкка йөгерүдә кызлардан Юля Тутаева (Урал федераль университеты) һәм егетләр арасында Тимур Әюпов (Казан федераль университеты) иң өлгерләр булып чыкты. Тимур безнең Физик культура һәм тернәкләндерү институтының V курсында белем ала. Йөгерү белән инде кечкенәдән профессиональ шөгыльләнә икән. Хыялы – Казанда үтәчәк Универсиадада катнашу. «Инде бүгеннән зур чарага ныклап әзерләнәбез», – ди Тимур. Кызлар арасында 400 м аралыкта III урынны шулай ук үзебезнең вуз студенты Яна Лысинская алды. Ул КФУның юридик факультетында V курста укый. Яна сер итеп кенә йөгерүнең укуга бер генә тамчы да комачауламавын әйтте.



Алия Галимуллина фотосы

**Лилия БӘДРЕТДИНОВА,**
хәбәрче

### *Өстәл теннисы*

Өстәл теннисын иң беренче булып Англиядә уйлап табалар һәм дөньякүләм таныталар. Бүгенге көндә өстәл теннисын уйнап карамаган кеше юктыр, миңа калса. Фестивальдә дә студентлар өстәл теннисында теләп катнашты.

Урал федераль университеты, Көньяк федераль университеты һәм М.К.Аммосов исемендәге Төньяк-көнчыгыш федераль университеты студентлары иртәрәк килеп, разминка ясыйлар иде. Өстәлнең бер башыннан бер башына очкан шар артыннан күзләр җитешә алмый. Шундый оста итеп уйныйлар... Уйнаганнарын озак кына карап тордым да тренерлары янына бардым. Ариан Тарасов күп еллар студентларын теннис уйнау серләренә өйрәтә. «Әлеге бәйгедә студентларыбыз яхшы нәтиҗәләргә ирешер дип өметләнәбез», – диде тренер.

### *Кул көрәше*

Кул көрәше тарихы да кызыклы. 1952 елда Америка журналисты Билл Соберанес иң беренчеләрдән булып кул көрәше буенча рәсми ярышлар уздыра. Бу уен төре шулай итеп тарихка кереп кала.

Көньяк федераль университетыннан килгән студентлар белән әңгәмә коргач, шунысы билгеле булды: әлеге спорт төре һәрдаим күнегүләр ясауны таләп итә. IV курс студенты Сергей инде мәктәп яшеннән бирле армрестлинг белән шөгыльләнә. Үзләренең округында күп тапкырлар беренчелекне ала. «Бу ярышта да сынатмаска иде дигән теләкләр белән килдем», – диде ул.

*Бу фестиваль яшь спортчыларга зур юллар ачты. 2013 елда узачак Универсиадада аларны тагын да югары үрләр һәм матур җиңүләр күтәрер дип ышанабыз!*

● Халыкара логопедлар көне

# Сөйләмебез төзеклеге

**Динә МӨХТӘСИПОВА,**
хәбәрче

«Мин татал сагыйльләленең сигыльләлен аелуча ялатып укыйм». Минем нәрсә әйтергә теләгәнне сез аңлап бетермәдегез. Ләкин бер һөнәр ияләре минем кимчелекне тиз сизеп алды!

Юк, корректорлар түгел... Логопедлар! Әйе-әйе, сөйләмнең кимчелекләрен юкка чыгару өстендә эшли алар. Укытучы-логопед авазларны дөрес әйтергә өйрәтә генә дип уйлаучылар нык ялгыша, чөнки аларның хезмәте күпкә катлаулырак. Алар телнең бөтен кимчелекләрен төзәтә: сөйләм тиешле дәрәҗәдә ачылып бетмәсә я ул бөтенләй булмаса, тавыш, сөйләмнең темпы һәм тембры бозылса, артык борчылырга кирәкми. Моның өчен логопедлар бар! Кызганычка каршы, мондый кимчелекләре булган кешеләр логопедларга мөрәҗәгать итәргә ашыкмый. Статистик мәгълүматларга караганда, әлеге проблеманың актуальлеге көннән-көн арта.

14 ноябрь – аларның һөнәри бәйрәмнәре. Халыкара логопедлар көне уңаеннан, Педагогика һәм психология институтының махсус психология һәм коррекцион педагогика кафедрасы үзләренә чын мәгънәсендә бәйрәм ясады. Биредә инде өченче ел рәттән «Логопедик калейдоскоп» дигән исем астында КВН оештырыла. II курс – «Тина Канделаки», IV – «Супер 8», ә V курс студентлары «Бал кортлары» исеме астында чыгыш ясады. 4 турдан торган бәйгене тынгысыз җанатарлар тагын да җанландырып җибәрде. Катнашучылар республика КВН командаларыннан бер дә ким түгел. Шаяртулары урынлы, мәгънәле, кызык. Һөнәргә бәйле проблемаларны күтәргән юмористик чыгышлар да булды. Студентлар бер үк вакытта яхшы белгеч һәм иҗат кешеләре булуларын исбатлады. Үз укытучыларыннан торган жюри дөрес бәя биреп, I урынга чыгарылыш курс студентларын тәкъдим итте. II курс студентлары бераз гына IV курслардан өстен чыкты.

Сөйләмдә сизелерлек кимчелекләре булган кешеләр саны артуын белгечләр үзләре дә яхшы аңлый. I курс студентлары әзерләгән видеоролик бер яктан кызык булып тоелса да, икенчедән, яшьләрнең бу өлкәдә бик сай йөзүен күрсәтте. Урамда очраган студентлардан логопедия, психологиягә бәйле терминнарның ни аңлатканын, махсус җиһазларның кайсы һөнәргә бәйле икәнен сорыйлар. Арада бер генә дөрес җавап бирүче дә табылмый.

Сөйләмне коррекцияләү процессы ата-анадан да, якыннардан да, баланың үзеннән дә зур көч һәм сабырлык таләп итә. Ләкин шул авыр һәм катлаулы юл киләчәктә зур уңышка илтергә мөмкин, чөнки бу эш белән иң тәҗрибәле кешеләр – укытучы-логопедлар шөгыльләнә!



■ *Рәсемдә: КВНчыларны бәяләүче жюри һәм җанатар-тамашачылар*

# «Карагыз, бу - нано!»

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

11 ноябрь көнне Казан федераль университетында «Карагыз, бу – нано!» күргәзмәсенең ачылу тантанасына ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм «Роснано» оешмасы рәисе Анатолий Чубайс килде. Күргәзмә 2 декабрьгә кадәр эшләячәк.



Алия Галимуллина фотосы

«Нанотехнологияләр атнасы» кысаларында ачылган күргәзмәдә иң уникаль наноматериаллар, энергия саклау технологияләре, алдынгы тикшеренү җиһазлары белән танышырга була. Әлеге атналык 2011 елның мартында ачылып, инде бик күп шәһәрләрне яулаган, йөздән артык фәнни-гамәли чаралар үткәрелгән. Казанлылар да битараф калмас дип уйлыйм.

«Нано – табигатьтә» дигән экспозициядә тере гекконнарны күрергә һәм лотосның үзенчәлекле якларын белергә мөмкин. 50 граммлы геккон 2 килограммга кадәр авырлыктагы әйберне күтәреп тора ала икән. Ә лотос яфраклары микроскопик энәләр белән капланганга, ул чыланмый, шуңа күрә әлеге чәчәкне чисталык символы дип тә атыйлар. Кызларны алар өчен уйлап табылган «кирпеч»ләр кызыксындырды. Пеноситал (пенопыяла) дигән материалдан ясалган әлеге «кирпеч»ләр үзләренең чиста, нык һәм озын гомерле булуы белән аерылып торалар. Мәктәп укучылары өчен тагын бер ачыш – карбоннан ясалган материал белән ныгытылган агач линейка! Гади линейканы сындыру бик җиңел, ә моны хәтта бөгеп тә булмый.

Р.Миңнеханов һәм А.Чубайс «Киләчәк әйбере» дигән рәсем конкурсы нәтиҗәләре белән дә таныштылар. Монда балалар үзләре уйлап табарга теләгән әйберләрне ясый. Бер укучыга хәтта А.Чубайс: «Нанодөньяда мегауңышлар теләп, Ильяга – Толя абыйсыннан», – дип язып калдырды. Ә Р.Миңнеханов Казан мәктәпләренә уңышлар теләде.

● «Иделем акчарлагы – 2011»

# Канат ныгыту

**Алмаз МАНСУРОВ,**
татар филологиясе бүлеге студенты

«Идел» яшьләр үзәге тарафыннан оештырылган «Иделем акчарлагы» бәйгесе быел унберенче тапкыр уздырылды. Бәйгенең проза номинациясендә Гран-при КФУның татар филологиясе бүлеге студенты Айгөл Абдрахмановага бирелде. Иң яхшы яшь шагыйрь дип Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты аспиранты Дания Нәгыймуллина танылды.

Конкурсның жюри рәисе Газинур Морат әйтүенә караганда, быел бәйгедә 100дән артык 14 яшьтән алып 30 яшькә кадәрге иҗат әһеле катнашырга теләк белдергән. Алар үзләренең эшләрен дүрт номинация буенча тәкъдим иткән. Традицион саналган поэзия, проза һәм драматургиядән тыш, бәйгедә кечкенәләр өчен балалар иҗаты номинациясе дә бар.

«Иделем акчарлагы» өч этапта үтә. Беренчесе – эшләрне кабул итү. Икенче этапта исә жюри әгъзалары эшләрнең иң лаеклыларын сайлап ала һәм катнашучыларның кайберләренә өченче этапта катнашу хокукын бирә.

Быелгы бәйгенең өченче этабы 12-15 ноябрь көннәрендә Петровский бистәсендәге «Регина» кунакханәсендә узды. Биредә катнашучылар язучы Р.Батулла, шагыйрьләр Г.Морат, Л.Лерон, И.Иксанова һ.б. белән очраштылар. Олпат шәхесләребез, иҗатлары белән таныштырудан тыш, бәйгедә катнашучыларга мастер-класслар үткәрде, яшь каләм әһелләренә киңәшләрен җиткерде. Программага музейга бару, спектакльләр карау, бөек шагыйребез Г.Тукай һәйкәленә чәчәкләр кую кебек чаралар да кертелгән иде.

Бәйгенең ябылу һәм җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы ТР Мәдәният министрлыгының конференцияләр залында узды. «Иделем акчарлагы»ның жюри рәисе Г.Морат үз чыгышында әлеге бәйгенең нәтиҗәләре сөендерерлек булуын ассызыклап узды. Аның фикеренчә, конкурс төрле төбәкләрдән җыелган яшьләрнең иҗатына бәя биреп кенә калмый, ә аларга үсү юлларын күрсәтә, камилләшергә ярдәм итә.

Шагыйрь, драматург, «Иделем акчарлагы» бәйгесенең жюри әгъзасы Л.Лерон яшьләрнең мәхәббәт темасына зур игътибар бирүләре, шулай ук милләтебез хакында борчылып иҗат итүләре хакында әйтеп узды.

Шулай итеп, поэзия номинациясендә I урын Лениза Вәлиевага, прозада исә Ләйлә Гатауллинага бирелде. Драма әсәрләре аз иде. Кызыксындыру бүләге – Алсу Айзатовага, ә I урын Башкортстаннан килгән Айдар Зәкиевкә тапшырылды. КФУның татар филологиясе бүлеге студенты Алмаз Мансуров поэзиядә – II, тәрҗемә белеме һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге студенты Ләйлә Хәбибуллина III урынга лаек булды. Балалар әдәбиятында исә Таңсылу Хәйретдинова белән Альберт Хәммәдиев бүләкләнде.

«Иделем акчарлагы»ның барлык катнашучылары да канәгать калгандыр дип уйлыйм. Ни өченме? Чөнки үзең кебек үк иҗади яшьләр арасында булу, аралашу күңелдә бетмәс илһам уята һәм киләчәккә яңадан-яңа кыю максатлар куярга ярдәм итә.

# Чит илдә дә – татарча

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

Үткән атнада Филология һәм сәнгать институтына төрле илләрдән, Россия, Татарстанның бик күп шәһәрләреннән килгән кунаклар – чит телле аудиториядә төрле телләрне укытуга зур өлеш керткән галимнәр «Чит тел буларак Россия һәм якын чит илләрдә яшәүче халыкларның телләре: укыту һәм өйрәнү» дип аталган халыкара конференциягә җыелды.

Аны рус теле кафедрасы, тәрҗемә белеме һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге ТР Министрлар кабинеты белән берлектә үткәрделәр.

Фойеда галимнәр һәм укытучыларыбызның хезмәтләре, дәреслекләре, методик кулланмалары зур күргәзмәдә урын алган иде. Бигрәк тә К.Фәтхуллова, Э.Денмөхәммәтовалар тарафыннан эшләнгән «Татар теле – күңелем теле» дигән аудиокурслы дәреслек һәм Л.Вербицкая, Лю Лиана, Е.Юркова редакциясендә чыккан «Русский язык и литература во времени и пространстве» китабы конференциядә катнашучыларның игътибарын җәлеп итте.



Динә Камалова фотосы

Пленар утырыш алдыннан Гиссен шәһәренең (Германия) Ю.Либих исемендәге университеты профессоры, филология фәннәре докторы Дамина Шайбаковадан интервью алганда, бу илдә татар теле белән кызыксынучылар бармы, дигән сорауга Дамина ханымның: «Әйе, кызыксынучылар бар. Безнең университетның шәрык телләре кафедрасында эшләүче немец галимәсе Рутбартоломеа татар теле бүлегендә татар теле дәресләре алып бара», – диюе телебез өчен горурлык хисләрен арттырды.

Конференция биш секциядән торды. Утырышларда үзләренең тәҗрибәләре белән рус һәм татар телле укытучылар гына түгел, казакъ, корея, украин һ.б. телләрне укыту өлкәсендәге белгечләр дә уртаклашты. Шулай ук чит телле аудиториядә белем биреп, инде күп еллар тәҗрибә туплаган галимнәр янәшәсендә яңа гына эшли башлаган яшь белгечләр дә уңышлы гына чыгыш ясадылар.

Ахырдан мондый фәнни-гамәли конференцияне ике елга бер мәртәбә үткәрергә һәм катнашучылар даирәсен тагын да киңәйтергә дигән фикер белән йомгак ясалды.

## Илһам канатында



**Ләйлә Хәбибуллина** 1993 елның 8 гыйнварында Буа районы Бик-Үти авылында дөньяга килә. Югары сыйныфларда укыганда, иҗат эшенә тартыла башлый, шигырьләр яза. Тормышны һәм дәреслекне ярата. Хәзерге вакытта тәрҗемә белеме һәм мәдәниятара багланышлар бүлегендә I курста белем ала.

***

*Күмерле йөрәкне*
*кимерә бу хисем.*
*Төн исе...*
*Бер сиңа,*
*Бер миңа –*
*Бер сөю.*
*Бер исем –*
*Аңлатма барсына.*
*Яратам...*
*Тик никтер*
*күңелем тарсына.*

***

*Күңелем тезләнеп каршыңа*
*баш ия...*
*Акылым сөюгә җиңелде.*
*Ә сиңа җиңелдер!*
*Гел көлеп йөрергә*
*Җавапсыз бу минем хисләрдән.*
*Искергән,*
*Кояшсыз төсләрдән*
*Мин гарык күптәннән...*
*Эз калды сагышлы яңгырлар*
*Ялкынлы йөрәкне үпкәннән.*

***

*Арылган буталган,*
*Чуалган хисләрдән.*
*Мин Ходай каршына*
*Кабаттан тезләнәм.*
*Сабырлык...*
*Бер генә уч сорыйм.*
*Күңелем бер дога*
*Кабатлар:*
*«Иңнәргә бир, Ходай*
*Канатлар.*
*Табарга сорауларга*
*Җаваплар.*
*Һәм тагын...*
*...Сабырлык.*
*Бер генә уч сорыйм».*

***

*Ят урамнар...*
*Фонарь яктысыннан*
*Тар салкынлык иңә.*
*Бармы икән берәү*
*Ял бирерлек*
*Минем йөрәгемә?..*

## Бәйге

# «Аңа заман шау-шуы ят...»

**Алисә БИЛАЛОВА,**
хәбәрче

Халыклар бердәмлеге көненә багышланган «Ватан - 2011» халык иҗаты республика яшьләр фестивале быел V тапкыр үткәрелә.





Республикабызда яшәүче талантлы яшьләрне барлау, аларны үстерүдә әлеге фестивальнең роле зур. Нәтиҗәләре дә юк түгел. Чараны оештыручыларның һәр төбәктән булачак йолдызларны эзләп табып, зур сәхнәгә чыгаруы – моның ачык мисалы.

«Ватан» фестиваленең быелгысы бөек Тукаебызның 125 еллыгына багышланды. Әлеге чараны оештыручылар – Татарстан халыклары ассамблеясе, ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм, Мәдәният, Мәгариф һәм фән министрлыклары, «Татарстан – яңа гасыр» телерадиокомпаниясе. Алар Татарстанда яшәүче халыкларның милли мәдәни традицияләрен саклап калу һәм җәелдерү, халыклар арасында толерантлык тәрбияләү, бердәмлек булдыру һәм, әлбәттә, талантлы яшьләребезгә ярдәм кулы сузу, аларны халыкка танытуны максат итеп куйган. Үзем фестивальнең башыннан ахырына кадәр катнашып йөргәнгә күрә, әлеге максатларга ирешелде һәм искиткеч бәйрәм оештырылды дияр идем.

Фестиваль ике елга бер тапкыр гына үткәрелә. Быел октябрь аенда Казан, Буа, Түбән Кама, Бөгелмә, Нурлат, Саба районнарында сайлап алу турлары булып узды. Җиде яшьтән алып утыз яшькә кадәрле егерме биш меңгә якын кеше көч сынашты. Иң-иңнәр генә, финалга кадәр барып җитеп, Казанда узган конкурс-фестивальдә катнашты.

1-4 ноябрь көннәрендә «Уникс» концертлар залында янәдән зур гына сайлап алу турлары узды. Татарстанда яшәүче төрле милләт вәкилләре ике көн көч сынашты. Чуаш, удмурт, мари халыкларының йолаларын күрсәттеләр, керәшенчә җырлап, татарча биеп тә бирделәр.

«Ватан» фестиваленең гала-концертында утызга якын коллектив катнашу бәхетенә иреште. Әлеге бәйрәмгә килгән тамашачы рус, татар, мари, азәрбайҗан, украин, чечен халыкларының биюләрен таң калып күзәтте. Фольклор коллективлары исә керәшен, удмурт халык йолаларын, татар халкының «Аулак өй», «Кияү мунчасы», «Күкәй җыю йоласы» кебек гореф-гадәтләрен, күңел ачу чараларын халыкка җиткерде. Гыйбрәтле шигырь, әкиятләр тыңлап, берсеннән-берсе матур, үзенчәлекле милли костюмнарны карап, моңлы җырлар аһәңендә чын мәгънәсендә бәйрәм рухы тоеп утырды тамашачы. Быел Гран-прига «Вокал-соло» номинациясендә чыгыш ясаган Әтнә районы егете Әлфис Кәримов лаек булды. Яшь булуына карамастан, үзенә генә хас милизмы, тавышы, моңы белән башка конкурсантлардан аерылып тора ул. Җиңүченең лаеклы бүләген ТР Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин үзе тапшырды.

«Әлеге фестиваль-конкурс башкалардан аерыла. Монда заман шау-шуы сизелми», – ди жюри рәисе, КФУ профессоры Миңгол Галиев. Чыннан да, монда берсен-берсе уздырып язган заманча музыка, кием дә юк. Сүзләрен халык аңламас хәлгә җиткереп җырлау, заманча бию дә әлеге фестивальгә ят күренеш. Монда бар да ихлас, самими, халыкча... Бәйгенең иң төп шарты: әзерләнгән номер халыкның гореф-гадәтен, йөзен ачык чагылдырырга тиеш.

Тамашачы күргәндер: бу көнне халык хәтерендә сакланган рухи байлыклар, әбиләрнең сандык төпләрендәге тарихи ядкәрләр сәхнә түренә менгән иде.

«Безнең ил, республика өчен әле бик яшь булган бу бәйрәм елдан-ел таныла, популярлаша бара, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Республикабызда 115ләп милләт вәкиле дус, тату, тыныч тормыш итkәннәр. Бу хәзер дә, бездән соң да шулай булачак».

Өйләргә таралышканда, күңелдә бары шатлык һәм канәгатьлек хисләре генә иде. Йөрәк еш-еш һәм куанып тибә. Белмим, әллә халкыбыз тарихының шулай матур итеп аваз салуы, әллә җиңү хисе шулай рухландыра аны.

## Студент эш эзли

# Филолог банкта эшли аламы?

**Резедә СӨНГАТУЛЛИНА,**
татар филологиясе бүлеге студенты



Энҗе Ибраһимова фотосы

Җәй җитеп, сессияләрне ябуга, студент аңында: «Җәйне ничек үткәрергә: ял итәргәме, әллә инде эшләп алыргамы?» - дигән сорау туа. Күпчелек, икенче вариантка тукталып, эш эзләргә керешә. Мин дә, җәйне файдалы һәм нәтиҗәле үткәрү максатыннан, эш эзләргә керештем.

Казанда эш табу кыен. Эш тапсаң да, эшләгән акчаң юлга, тукланырга, фатир өчен түләүгә генә китәчәк. Шуңа күрә, тәвәккәлләп, районга кайтырга булдым.

Узган елгы җәйдә мин Кайбыч муниципаль районының «Өмет» халыкка социаль ярдәм күрсәтү үзәгендә эшләдем. Районыбызда яшәүче өлкәннәргә ярдәм итү, балигъ булмаган балалар, проблемалы гаиләләр белән эшләү, «Балага мәктәпкә җыенырга ярдәм ит» акциясендә катнашу миңа ошады. Инде тәҗрибәм дә бар, коллектив та таныш дигәндәй, быел да шунда эшләргә теләдем, тик анда студентларны кабул итмәделәр. Өметне өзмәдем, эзләнүгә керештем.

Безнең «Миләшкәй» балалар бакчасына ел саен студент кызларны эшкә алалар. Мин дә мөрәҗәгать итеп карарга булдым. Булачак һөнәрем дә балалар белән бәйләнгән, балаларны да яратам. Эш тәртибе белән таныштырдылар: биредә эш сәгате иртәнге 7.30дан кичке 17.30га кадәр, төшке ашсыз, ял көне – якшәмбе. Бу графикны ишеткәч, ничектер сагаебрак калдым, көне буе балалар белән эшләү зур җаваплылык та сорый бит.

Район шифаханәсендә 2 көн медицина тикшеренүе үтүем юкка булып чыкты. Ник дигәндә, «Саклык банкы»на промоутер кирәк? Эшләргә теләгең юкмы?» – дип әнием шалтыратты. Башта шикләнсәм дә, тәвәккәлләп барып карарга булдым. «Саклык банкы» җитәкчесе барлык шикләремне таратты. «Безгә синең нинди белем алуың мөһим түгел, иң мөһиме – син актив, аралашучан, максатчан булырга тиеш».

Күпмедер вакыттан соң банктан шалтыратып, эшкә урнашуымны, Буага барып, промоутерлыкка укырга кирәклекне хәбәр иттеләр. Менә шулай промоутерга әйләндем.

Үземне шул өлкәдә сыный башладым. Төп эшем түбәндәгедән гыйбарәт: озакламый пенсияне кулга бирми башлаячаклар. Пенсионерлар лаеклы ял акчаларын пластик карталар ярдәмендә алачаклар. Банклар арасында көндәшлек туа. «Саклык банкы» пенсионерларга беренчеләрдән булып пластик карталар тәкъдим итә башлый. Күптән вакыт дияр берәүләр. Олы яшьтәге кайбер абый-апаларга мондый техниканы аңлавы шактый авыр булса, кайберләре, әйтик, яшьрәк пенсионерлар, бу яңалыкка сөенәләр генә.

Беренче эш көннәре, билгеле, авыррак иде. Зур коридорда урын бирделәр. Бөтен кергән-чыккан халыкның күзе миндә. Пенсионерлар белән эшлисе булгач, һәр кергән пенсионерга мөрәҗәгать итәм, пластик карта алырга тәкъдим ясыйм. Кайбер кешеләргә пенсионер дип дәшеп үпкәләткән чаклар да булды. Шуңа күрә «Пенсионерлар өчен яңалык» дигән язу элеп куйдым. Кызыксынучылар саны артты. Яшьрәк пенсионерлар пластик картаны теләп алдылар. Сирәк булса да, өлкәнрәкләр арасында да карта алырга теләк белдерүчеләр булды. Әйтик, 1929 елгы Сәвия апа кыш чыгарга балаларына шәһәргә җыена, билгеле, ул пенсиясен алыр өчен генә авылга кайтып йөрмәячәк. Ринат абый шәһәргә китеп эшкә урнашкан, әмма пропискасы авылда һәм ул, пенсиясен алыр өчен, гел авылга кайта торган булган. Равия апа да бик шатланды: «Еш кына шәһәргә барам, почтальон пенсияне өйгә китерә дә ирем мин кайтканчы акчаны эчеп бетерә», – дип сөйләде һәм карталы булды.

Яшьли әтисез, ятим, инвалид калган яшүсмерләр дә бар. Кайберләре республикабызның төрле уку йортларында белем ала, туган авылларына сирәк кайталар, андыйлар да картаны алдылар.

Күбесе яңалык белән кызыксынды, тик, авылларында банкомат булмау сәбәпле, картага күчү уеннан кире кайтты. Һәр авылда филиал һәм банкомат булса, эшләр башка юнәлеш алган булыр иде, әлбәттә.

Ә мин исә күп кенә кешене пластик карталы итүемнән канәгатьмен. Промоутер эше миңа уңай эмоцияләр бүләк итте. Яңа дуслар таптым. Үземнең аралашучанлык, коллектив белән эшли белү, җаваплылык кебек сыйфатларга ия булуымны аңладым.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ

Тираж 999

Мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, Л.Н.Бәдретдинова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты

Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Сул Болак ур., 44 й., 6 Б каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: (843) 292-22-91, 89053711571.
Электрон почта: tggpu-tat@yandex.ru. Сайт: ksu.ru

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.

Газета бушлай таратыла